РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» декабрь 2024г. г. Альметьевск №161

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 11 маендагы 113 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль - хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары» нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 11 маендагы 113 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2020 елның 30 октябрендәге 8 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 58 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 67 номерлы, 2022 елның 5 октябрендәге 82 номерлы, 2022 елның 28 декабрендәге 92 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 145 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү тәртибендә һәм шартларында:

1.1.1. механизм карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

(сум)

| «Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 38 333 |

| | |
|---|---|
| Идарә башлыгы, мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе | 26 581 |
| Идарә башлыгы урынбасары, мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары, башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 22 245 |
| Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе, башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 22 245 |
| Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек җитәкчесе | 22 245 |
| Сектор мөдире | 20 846 |
| Баш белгеч | 20 426 |
| Әйдәп баручы белгеч | 19 167 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 17 768» |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестникгазетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»на (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 январеннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.А.).

Шәһәр Башлыгы вазыйфаларын башкаручы И.Р. Баһманов